ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

"21" октябрь 2024 ел Мусабай-Завод авылы № 17

**"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кзыл-Байрак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы "Мусабай-Завод авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Советы 08.11.2019 ел, № 49/2 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында» карары белән

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кзыл-Байрак авылында 2024 елның 03 ноябрендә 11.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Мусабай-Завод авыл җирлегенең Кзыл-Байрак авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Мусабай-Завод авыл җирлегенең Мусабай-Завод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
-юллар салу эшләрен башкару, юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү;
- урам утларын ремонтлауны хәл итүгә (урам фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру) юнәлдерүгә килешәсезме

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Кзыл-Байрак авылы, Үзәк урамы, 7б йорты.

4. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы З.З. Хөсәинова